КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 19 декабрь г.Казань № 1172

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Кызыл китабы турында» 1993 ел, 25 октябрь, 615 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 ел, 22 июнь, 419 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Кызыл китабы турында» 1993 ел, 25 октябрь, 615 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 ел, 22 июнь, 419 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән үсемлекләр һәм гөмбәләр төрләренә (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән төрләрдән тыш) карый торган үсемлекләрне һәм гөмбәләрне законсыз җыю яки юкка чыгару аркасында салынган зыян өчен акча түләтү күләмен исәпләү өчен таксаларны (карарга теркәлә) расларга.»;

4 пунктта «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган хайваннарның, үсемлекләрнең һәм гөмбәләрнең Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән төрләре (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән төрләрдән тыш) исемлекләре үз көчен югалткан дип санарга;

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән үсемлекләр һәм гөмбәләр төрләренә (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән төрләрдән тыш) карый торган үсемлекләрне һәм гөмбәләрне законсыз җыю яки юкка чыгару

аркасында салынган зыян өчен  акча түләтү күләмен исәпләү өчен таксаларны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәләләр);

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайваннар төрләренә (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән төрләрдән тыш) карый торган  хайваннарны законсыз аулау яки юкка чыгару аркасында салынган зыян өчен акча түләтү күләмен исәпләү өчен таксалар үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                    А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2009 ел, 22 июнь, 419 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 19 декабрь, 1172 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән үсемлекләр һәм гөмбәләр төрләренә (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән төрләрдән тыш) карый торган үсемлекләрне һәм гөмбәләрне законсыз җыю яки юкка чыгару аркасында салынган зыян өчен акча түләтү күләмен исәпләү өчен таксалар

| Үсемлекләр, гөмбәләр төркемнәре | Үлчәү берәмлепге | Түләтү күләме, сум |
|---|---|---|
| Зурлыгына бәйсез 3 елдан өлкән яшьтәге агачлар, куаклар | нөсхә | ылыслылар – 50 000, яфраклылар – 30 000 |
| Зурлыгына бәйсез 3 елга кадәр яшьтәге агачлар, куаклар | нөсхә | 10 000 |
| Зурлыгына бәйсез үлән үсемлекләр | нөсхә | 200 |
| Зурлыгына бәйсез гөмбә | данә | 150 |
| Мүк яки мүккә охшашлылар | кв.метр | 15 000 |
| Зурлыгына бәйсез суүсемнәр | килограмм | 1 000 |